# ЮЛИЯ ЕФИМОВА: “МИН ЯУЛАГАН АЛТЫН РОССИЯ ЙӨЗҮЧЕЛӘРЕН КИЛӘСЕ БАТЫРЛЫКЛАРГА РУХЛАНДЫРЫР ДИП ЫШАНАМ”

04.08.2015, 20:30

СПОРТ

Хатын-кызлар арасында брасс белән 100 метр дистанциягә йөзү буенча Дөнья чемпионкасы россияле Юлия Ефимова журналистлар белән әңгәмәсендә Казандагы ДЧ-2015тә тамашачылар тулы трибуналар алдында чыгыш ясаганда ни өчен дулкынланганы турында сөйләде.

“Күрсәткечем бик әйбәт булмаса да, 100 метрлы дистанциядә җиңү яулавыма мин бик шатмын. Алтын алтын инде ул. Командага беренче алтын медаль алып килүемә шатмын һәм безнең җыелма команданы киләсе батырлыкларга рухландырдым дип ышанам. Ни өчен Рута икенче кисәктә акрынайдымы? Без барыбыз да дулкынландык. Анда бигрәк тә киеренке момент булды. Дөнья чемпионатының хуҗалары үзебез булганлыктан, бу йөзештә мин җиңелә алмый идем. Шәхсән үзем шуның өчен борчылдым. Соңгы 15 метрда бөтен кызлар да ардылар. Барысы да кемнең һәм ничек итеп финалга килүеннән тора иде”, - дип сөйләде Ефимова.

Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА